**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4570**
**14.09.2020**

Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын раслау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия төзү турында» 2017 елның 11 июлендәге 473 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә, шәһәр территориясендә сугыш вакытында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр шартларында оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү максатында

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия составын 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4570 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясенең (алга таба - комиссия) статусын һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

2. Комиссия хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның куркынычсыз яшәеше өчен кирәкле шәһәр оешмалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатында төзелде.

3. Комиссия сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны планлаштыруны һәм үтәүне гамәлгә ашыручы даими эшләүче орган булып тора.

4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

5. Комиссия составы Башкарма комитетның җитәкче составыннан һәм килешү буенча җәлеп ителә торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны планлаштыруны һәм үтәүне оештыру;

2) икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын, гражданнар оборонасының инженерлык-техник чаралары таләпләренә туры китереп, рациональ урнаштыру;

3) куркыныч янаган чорда комплекслы маскировка үткәрү;

4) энергия һәм су белән тәэмин итү системалары һәм чыганаклары эшчәнлегенең ышанычлылыгын арттыру;

5) тыныч вакытта һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын, шул исәптән төзелеш проектларында эшләү һәм тормышка ашыру;

6) сугыш вакытында эшне дәвам итә торган икътисад объектларында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү;

7) җитештерү процессын торгызу һәм халыкның тормыш-көнкүрешен саклап калу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан булдыру;

8) документларның иминият фондын булдыру;

9) житештерү фондларына заманча зарарлану чаралары тәэсир иткәндә, аларны саклауның нәтиҗәлелеген арттыру.

7. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) сугыш вакыты шартларында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны планлаштыру һәм үткәрү;

2) оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча тикшеренү эшләрен үткәрү;

3) сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар тарафыннан эшчәнлекләренең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның тормышка ашырылуын бәяләү;

4) оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыруга, сугыш вакыты һәм гадәттән тыш хәлләр шартларында оешмалар персоналын һәм халыкны яклауга юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү һәм аларны Башкарма комитетка тапшыру;

5) шәһәр территориясендә оешмалар тарафыннан төзелә торган эшчәнлек тотрыклылыгын арттыру буенча комиссияләр белән үзара хезмәттәшлек;

6) оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның үтәлешен, шул исәптән вазыйфаи затларны һәм җитәкчеләрне, эшчәнлек тотрыклылыгын арттыру буенча тиешле комиссияләр вәкилләрен тыңлау юлы белән анализлау;

7) сборларда, өйрәнүләрдә, тренировкаларда һәм башка пландагы чараларда катнашу.

8. Ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать производствосы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

1) гадәттән тыш хәлләрдә һәм сугыш вакыты шартларында электр һәм җылылык белән тәэмин итү, су һәм ягулык белән тәэмин итү элементларының һәм системаларының тотрыклылык дәрәҗәсен билгеләү;

2) шәһәр территориясендә оешмаларның автоном энергия белән тәэмин итү чыганакларыннан эшләү мөмкинлекләрен анализлау;

3) сәнәгать предприятиеләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелеген бәяләү;

4) төп житештерү фондларының ихтимал булган җимерелү дәрәҗәсен һәм предприятиеләрнең җитештерү куәтләрен югалтуларны бәяләү;

5) шәһәр территориясендә ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать производствосы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

9. Торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

1) торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелеген анализлау;

2) шәһәр территориясендә торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

10. Транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

1) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелеген анализлау;

2) транспорт чараларының ихтимал булган югалтуларын һәм транспорт коммуникацияләренең һәм алардагы корылмаларның ихтимал булган җимерелүләрен билгеләү;

3) шәһәр территориясендә транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

11. Социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

1) социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелеген анализлау;

2) шәһәр территориясендә социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

12. Идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

1) идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелеген, шул исәптән төп идарә органнары белән элемтә бозылганда, кабатлаучы идарә органнарының оешмалар белән өзлексез идарә итүне тәэмин итү сәләтен анализлау;

2) барлык дәрәҗәдәге идарә органнарының җитәкчелек составына һәм шәһәр халкына хәбәр итү системасының әзерлеген анализлау;

3) шәһәрнең идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

13. Үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру максатларында комиссия хокуклы:

1) комиссиягә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны оешмалардан соратып алырга;

2) кызыксынган фәнни-тикшеренү һәм башка оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең белгечләрен оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләрен карап тикшерүгә билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

3) оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә тикшеренүләр эшләүне һәм үткәрүне башлап җибәрергә һәм үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча эшләнгән чараларны практик гамәлгә ашыруның максатчанлыгын карарга;

4) оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә тикшеренүләр үткәрүдә катнашырга;

5) җитәкчеләрне һәм вазыйфаи затларны чакырып комиссия утырышларын үткәрергә һәм оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча үткәрелә торган чаралар буенча аларны тыңларга.

## 2 бүлек. Комиссиянең вәкаләтләре һәм эш тәртибе

14. Комиссия, аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча, хокуклы:

1) тиешле хезмәтләрдән комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

2) билгеләнгән тәртиптә утырышлар, координацион киңәшмәләр һәм эш очрашулары оештырырга һәм үткәрергә;

3) комиссия утырышында катнашу өчен комиссия эшчәнлеге өлкәсенә караган өлкәләрдә махсус белемнәре булган белгечләрне чакырырга;

4) үз компетенциясе чикләрендә, оештыру-хокукый формаларына һәм ведомство карамагына бәйсез рәвештә, барлык оешмалар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган тиешле карарлар кабул итәргә.

15. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

16. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана. Комиссиянең сан ягыннан составы 5 кешедән дә ким була алмый.

17. Комиссия белән, комиссия эшен оештыручы рәис җитәкчелек итә.

18. Комиссия әгъзалары вәкаләтле:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия рәисенә комиссия утырышын кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

3) комиссия утырышында катнашырга;

4) комиссия каравына кертелгән мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

5) комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча карарлар кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга.

19. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) утырышны үткәрү урынын һәм вакытын, көн тәртибенә керүче мәсьәләләр даирәсен билгели;

2) комиссия утырышларында рәислек итә;

3) комиссия эшен аның бурычлары нигезендә оештыра, комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек һәм контроль аша, йөкләнгән бурычларның үтәлешен тәэмин итә;

4) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны имзалый.

20. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара.

21. Комиссия секретаре бурычлы:

1) чираттагы елга комиссиянең эш планын эшләргә һәм килештерүне оештырырга;

2) комиссия утырышлары үткәрүне оештырырга;

3) утырышны үткәргәнче 3 көн алдан, комиссия әгъзаларына һәм катнашучыларга аның датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында хәбәр итәргә;

4) утырышлар беркетмәләрен алып барырга һәм аларның йомгаклары буенча карарлар рәсмиләштерергә;

5) комиссия карарларын башкаручыларга җиткерүне оештырырга һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга.

22. Комиссия утырышы комиссия рәисе яисә аны алмаштыручы зат карары буенча чакырыла. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

23. Комиссия эшчәнлеге даими нигездә гамәлгә ашырыла. Әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашса, комиссия утырышлары тулы хокуклы дип санала. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

24. Комиссия карары рәис тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләрнең күчермәләре, башкару өчен, өч көн срокта комиссия әгъзаларына һәм утырышка чакырылган затларга җибәрелә.

25. Шәһәр территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны турыдан-туры планлаштыру, гамәлгә ашыру һәм башкаруны контрольдә тоту өчен комиссия тарафыннан эшче төркемнәр төзелә:

1) ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать производствосы һәм транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

2) торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

3) социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

4) идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча.

26. Эшче төркемнәр составы Башкарма комитетның җитәкче составы һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре арасыннан төзелә.

27. Ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать производствосы һәм транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

1) ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны фаразлауны һәм планлаштыруны;

2) ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлауны;

3) ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылык дәрәҗәсен билгеләүне:

4) ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне;

5) сәнәгать предприятиеләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны фаразлауны һәм планлаштыруны;

6) сәнәгать предприятиеләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген бәяләүне;

7) төп җитештерү фондларының ихтимал булган җимерелүләрен һәм әлеге предприятиеләрнең җитештерү куәтләрен югалтуларны анализлауны;

8) шәһәр территориясендә сәнәгать предприятиеләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру, җитештерү көчләрен урнаштыруны яхшырту һәм хуҗалык элемтәләренең ышанычлылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне;

9) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны фаразлауны һәм планлаштыруны;

10) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлауны;

11) транспорт чараларының һәм корылмаларның (тимер юл станцияләренең һәм юлларның, ремонт предприятиеләренең, күперләрнең) ихтимал булган югалтуларын һәм җимерелүләрен  билгеләүне;

12) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне.

28. Торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

1) торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны фаразлауны һәм планлаштыруны;

2) торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлауны:

3) торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылык дәрәҗәсен билгеләүне;

4) торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне.

29. Социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

1) социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны фаразлауны һәм планлаштыруны;

2) социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлауны;

3) социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылык дәрәҗәсен билгеләүне;

4) социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне.

30. Идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

1) идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларын фаразлау һәм планлаштыруны;

2) идарә һәм элемтә системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлауны, шул исәптән дублерларның төп идарә

органнары белән элемтә бозылганда оешмалар белән идарә итүне тәэмин итү сәләтен анализлауны;

3) идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылык дәрәҗәсен билгеләүне;

4) буйсынучылар һәм югары идарә органнары белән элемтә һәм идарә системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне.

31. Эшче төркем җитәкчесе бурычлы:

1) үзенә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр нигезендә эшче төркем эшен оештырырга;

2) комиссиянең еллык планын эшләүдә катнашырга;

3) комиссия рәисе һәм аның урынбасарының аерым йөкләмәләрен үтәргә;

4) эшче төркемгә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр чикләрендә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелегенә анализ үткәрүне оештырырга;

5) эшче төркемгә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр чикләрендә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр эшләргә.

32. Эшче төркемнәрнең эш тәртибе һәм планнары комиссия эш планы нигезендә аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4570 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә
оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Кропотова Наталия Анатольевна | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Кашихин Евгений Викторович | комиссия рәисе урынбасары, ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 3. | Матросов Рәмзи Таһир улы | комиссия секретаре, Татарстан Республикасы ГТХМ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| | | комиссия әгъзалары: |
| 4. | Гыйлаҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| 5. | Каширина Галина Михайловна | социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәрендәге социаль яклау идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 6. | Парамонов Максим Геннадьевич | ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать производствосы һәм транспорт өлкәсе эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, транспорт һәм элемтә бүлеге башлыгы |
| 7. | Ситдыйков Салават Әнәс улы | торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева